ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**09.12.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3152**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 07 сентябрендәге 2176 номерлы карары белән расланган, җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 21 октябрендәге «Россия Федерациясе субъектларында инвестицион климат торышының Илкүләм рейтингы күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасының инвестицион климаты торышын яхшырту чараларын гамәлгә ашыру турында» 991 номерлы карарына туры китереп, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 п. 1 п. п. таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 07 сентябрендәге 2176 номерлы карары белән расланган, җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.
1.1. 2.5.2 пунктының 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«7) җир асты коммуникацияләре, корылмалары, шулай ук җир кишәрлекләре хуҗалары булган кызыксынган оешмалар белән килештерү (челтәр оешмалары тарафыннан башкарыла торган энергия кабул итүче җайланмаларны технологик тоташтыру очракларыннан тыш)».
2. Әлеге карарны ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигына «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В.Старостин